СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 18, с.Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 18 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366) 94-2-37, факс (84366) 94-2-37. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**« 19 » октябрь 2017 ел** **№ 20**

**Төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Апаз авыл җирлеге Уставы, Апаз авыл җирлегендә, Апаз авыл җирлеге Советының 2009 елның 19 октябрендәге 108 номерлы карары белән (2012 елның 06 февралендәге 26 номерлы үзгәрешләр белән) расланган Апаз авыл җирлегендә халык хокукларын муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу өчен гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. Апаз авыл җирлегенең Җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларын 07.11.2017 елга билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны Апаз авыл җирлеге Советының «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карар проекты буенча 10.00 сәгатьтә ТР, Арча муниципаль районы, Апаз авылы, Совет урамы, 18 йорт адресы буенч аүткәрергә.

3. Апаз авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә тәкъдим ителә торган үзгәрешләр буенча гражданнарның тәкъдимнәре, искәрмәләре һәм гавами тыңлауларда катнашуга гаризалары язмача рәвештә 16 сәгатькә кадәр җибәрелә дип билгеләргә. 07.11.2017 елга кадәр түбәндәге адрес буенча җибәрергә: ТР, Арча муниципаль районы, Апаз авылы, Совет ур., 18 й., тел.88436694237.

4. Әлеге карарны һәм Апаз авыл җирлеге Советының «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карары проектын Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru), Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Садиков